ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы, 422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

17.11.2020 № 02

На № ______________ от ________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Нариман авылында халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Нариман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: -Нариман авылының Эшчеләр урамы буенча юл төзелеше, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 70 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 63 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - 58 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен - 5 җыен катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Нариман авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Нариман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Нариман авылында 2021нче елда 1000 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча : - Нариман авылының Эшчеләр урамы буенча юл төзелеше, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены карарын танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Нариман авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Майоров